РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ
ТЕТЮШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422370 г.Тетюши, ул. Малкина, 39

ТАТАРСТАНРЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422370 Тәтеш шәһәре, Малкин ур., 39

тел. (84373) 2-50-02, 2-53-33, факс 2-62-48, e-mail: tatesh@tatar.ru
ОКПО 78702080, ОГРН 1061672000026, ИНН/КПП 1638004985/163801001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
08.06.2020

**КАРАР**
№ 268

**Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетының «Мәктәпкәчә белем бирү программаларын тормышка ашыручы мәгариф оешмалары эшчәнлеген финанслау нормативларын раслау турында»гы 2019 елның 19 ноябрендәге 804 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнехановның 2020 елның 26 маенда үткәрелгән киңәшмәдә, мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында ата-аналар түләве күләмен формалаштыруга якын килүне үзгәртү мәсьәләсе буенча бирелгән боерыгын үтәү максатыннан, шулай ук, «Тәтеш шәһәренең «Әкият» катнаш төрдәге балалар бакчасы» МБМББУнең компенсация юнәлешендәге төркем контингентын саклау максатларында, Тәтеш муниципаль районы башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетының «Тәтеш муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын тормышка ашыручы мәгариф оешмалары эшчәнлеген финанслау нормативларын раслау турында»гы 2019 елның 19 ноябрендәге 804 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2019 елның 19 ноябрендәге 804 номерлы карарның 1 пунктындагы бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына кергән балага ата-ана түләве күләменә (азык-төлек бәясеннән тыш) түбәндәге төзәтмәләр коэффициентларын 2020 елның 1 гыйнварына кадәр билгеләргә:

| Мәктәпкәчә белем бирү учреждениясенең тнага эш көннәре саны | Мәктәпкәчә белем бирү учреждениясенең эш сәгатьләре саны | Күчмә периодка төзәтмә коэффициентлар | |
|---|---|---|---|
| | | 2 айдан алып 3 яшькә кадәр | 3 яшьтәп алып 7 яшькә кадәр |
| 5 эш көне | 9 | 1,00 | 0,78 |
| | 12 | 1,00 | 0,96 |

1.2. 2019 елның 19 ноябрендәге 804 номерлы карарының «Тәтеш муниципаль районы мәктәпкәчә белем бирүнең төп белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында балаларны караган һәм караган өчен ата-аналар түләве күләме» турындагы кушымтасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Гомуми үсеш һәм катнаш юнәлештәге төркемнәрдә мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмаларында балаларны караган өчен ата-аналар түләве күләме

| Мәктәпкәчә белем бирү учреждениясе нең атнага эш көннәре саны | Мәктәпкәчә белем бирү учреждения сенең эш сәгатьләре саны | Балалар саны | Бер тәрбияләнүче өчен ата-аналар түләвененң күләме, аена сум | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Барлыгы | | Шул исәптән, азык-төлек продуктларының күләме | |
| | | | 2 айдан 3 яшькә кадәр | 3 яшьтән белем бирүне туктатуга кадәр | 2 айдан 3 яшькә кадәр | 3 яшьтән белем бирүне туктатуга кадәр |
| 5 эш көне | 9 | 3 яшьтән | 2 835 | 3 120 | 1 938 | 2 442 |
| | | 3тән күбрәк | 1 418 | 1 560 | 969 | 1 221 |
| | 12 | 3 яшьтән азрак | 3 018 | 3 252 | 1 938 | 2 442 |
| | | 3тән күбрәк | 1 509 | 1 626 | 969 | 1 221 |

2) Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балаларның бер һәм аннан күбрәк категориясен физик һәм (яки) психик үсешендә җитешсезлекләрне квалификацияле коррекцияләү эшчәнлеген өстенлекле гамәлгә ашыру белән компенсацияләүче төркемнәрдә мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә

ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларында балаларны караган өчен ата-аналар түләве күләме

<table>
<tr><td rowspan="4">Мәктәпкәчә белем бирү учреждениясенең атнага эш көннәре саны</td><td rowspan="4">Мәктәпкәчә белем бирү учреждениясенең эш сәгатьләре саны</td><td rowspan="4">Балалар саны</td><td colspan="2">Бер тәрбияләнүче өчен ата-аналар түләвенең күләме, аена сум</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>Шул исәптән, азык-төлек продуктларының күләме</td></tr>
<tr><td>Сөйләмнәрендә фонетик-фонематик бозылулар булган балалар</td><td>Сөйләмнәрендә фонетик-фонематик бозылулар булган балалар</td></tr>
<tr><td>3 яшьтән күбрәк</td><td>3 яшьтән күбрәк</td></tr>
<tr><td rowspan="2">5 эш көне</td><td rowspan="2">12</td><td>3тән кимрәк</td><td>3352</td><td>2 442</td></tr>
<tr><td>3 яшь һәм аннан күбрәк</td><td>1676</td><td>1 221</td></tr>
</table>

2. Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетының «2020 елга Тәтеш муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын тормышка ашыручы мәгариф оешмалары эшчәнлеген финанслау нормативларын раслау турында»гы 2019 елның 19 ноябрендәге 804 номерлы карарын теркәлгән кушымтага үзгәрешләр кертү турында»гы 2020 елның 7 февралендәге 80 номерлы карарын үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2020 елның 12 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуну «Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ начальнигы Г.Ф. Кирилинга йөкләнә.

**Тәтеш муниципаль районы**
**башкарма комитеты җитәкчесе** **А.Б. Семенычев**